
Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ

12+


№13 (143)

9 октябрь 2015 ел













Никита Тохтасинов фотолары

# Җыр-биюле студент чак мәңге истә калачак

КФУда кабат фестиваль гөрли. Беренче курслар сәнгатьтә көч сынаша. Чыгышлары исә дәрәҗәле казыйлар тарафыннан бәяләнә. Җиңүчеләр бик тиздән билгеле булачак! Концертта яңа буын бөтен талантын күрсәтеп, сөйләп, дәлилләп бирергә тырыша. «Беренчеләр»нең сәләте, сәхнәдә үз-үзен тоту рәвешләре, җыр-биюдәге осталыклары уңай фикер калдыра. Шунысы куандыра: ел саен сәләтле яшьләр килә икән!

Мөнбәр

# КФУ дөньяга танылa

Руфинә ГАБДРАХМАНОВА

Казан федераль университетында белем алучы һәр яшь кеше зур горурлык хисе кичерә, чөнки уку йортыбыз дөньяның иң яхшы университетлары рейтингында үзенең лаеклы урынын тапты.




Дөньяның иң яхшы университетлары рейтингы (The World University Rankings) – кин күләмдә уздырыла торган махсус тикшеренү ул. Әлеге эш Times Higher Education (THE) дип аталган абруйлы Британия басмасы методикасы ярдәмендә башкарыла.

Университетның казанышлары статистик анализ һәм аудит мәгълүматларына нигезендә бәяләнә. Шулай ук университет турында үз фикерен белдерүчеләр бәясе дә исәпкә алына. Мондый сораштыру, гадәттә, академик фән өлкәсе вәкилләре һәм эш белән тәэмин итүчеләр арасында оештырыла.

Иң-иңнәрне сайлап алганда уку йортларын 13 төрле күрсәткеч буенча тикшерәләр. Бу күрсәткечләрне 5 төркемгә берләштереп булыр иде: белем бирү (бәянең 30%ын бирә), халыкара репутация (7.5%), фәнни мәкаләләрнең цитаталануы (30%), уку йортының сәнәгать үсешендә катнаша алу мөмкинлеге (2.5%), фәнни тикшеренү дәрәҗәләре (30%).

Фәнни мәкаләләрнең цитаталану дәрәҗәсе буенча 87,5 балл җыеп, КФУ әлеге рейтингта югары урынга лаек булды.

Ректор Илшат Гафуров әлеге уңышны күп көч таләп итә торган системалы хезмәт нәтиҗәсе буларак бәяли. Чынлап та, соңгы елларда дөнья күләмендә абруй казану юнәлешендә шактый эш башкарылган. Мисал өчен, университетның үсеше Программасы кысаларында (ул 2010 елда кабул ителгән иде) фән һәм белем бирү инфраструктурасына 7,4 млрд сумнан артык акча бүленгән. 415 фәнни һәм укыту лабораториясе булдырылган, алар заманча җиһазландырылган.

«Университетның халыкара рейтингта тоткан урынына тәэсир итүче иң әһәмиятле дүрт юнәлештә сизелерлек уңышка ирешә алдык, – ди ректор. – Беренчесе – фәнни мәкаләләрнең басылу активлыгы. Халыкара журналларда басылган мәкаләләр саны соңгы биш елда 5 тапкыр артты – 280нән 1543кә кадәр күтәрелде. Икенчесе: мәкаләләрнең саны гына түгел, сыйфаты да яхшырды. Өченче өлкә – университетның сәнәгать белән хезмәттәшлеге үсеше. Фәнни-тикшеренү һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләнмәләреннән керем, бер фәнни-педагогик хезмәткәргә исәпләгәндә, 3 мәртәбәгә артты. Бу күрсәткеч буенча университетыбыз дөньяда 317 нче урынга чыкты. Дүртенчесе – чит ил студентларының КФУда белем алу, фәнни тикшеренүләр белән кызыксыну дәрәҗәсе. 2013 елда чит ил студентларының саны барлык укучыларның 3,1%ын тәшкил иткән булса, 2015 елда инде бу күрсәткеч 7% ка житте».

Дөньяның иң яхшы университетлары арасында югары урынга лаек булу вуз эшчәнлеге өчен зур күрсәткеч санала. Шуны искәртеп китү мөһим: бу рейтингта Россиядән 13 югары уку йорты бәяләнгән, КФУ шулар арасында 4 нче урында.

Мәгълүмат һәм диаграмма timeshighereducation.com сайтыннан алынды.

Белем буразналары

# «Yaz okulu-2015»

Гүзәл ГАЛИЕВА, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегенең бер төркем студенты Төркиянең Юныс Әмрә институты оештырган җәйге курсларында гыйлем алырга ерак сәфәргә барды. «Yaz okulu-2015» («Җәйге мәктәп – 2015») дәресләренә дөньяның 60лап иленнән 500 укучы килгән иде.

Төрек теле укытучыбыз Р.Р.Хөснетдинов безне Истамбул шәһәре белән таныштырды. Сонрак, телне тирәнрәк өйрәнер өчен, төркемебезне Бурса, Айдын, Коджаэли, Невшехир, Зонгулдак төбәкләренә бүлеп җибәрделәр. Төркия табигате безне үзенең гаҗәеп гүзәллеге белән җәлеп итте. Чыннан да, төрки кардәшләребез төрекләрнең ватаны күңелгә гаять якын булды. Невшехир дә бик үзенчәлекле, тарихи ядкярләргә бай шәһәр. Таулы, калкулыклы, гаять гүзәл географик мохиттә хасыйл булган «эшләпәле» Каппадокия ташлары күбегезгә мәгълүмдер, мөгаен.



Безне Невшехир университетының кунакханәсенә урнаштырдылар. Әйе, әйе, сез ялгыш ишетмәдегез, университетның үз кунакханәсе дә бар икән! Невшехир төркемендә төрле илләрдән килгән 24 талибтәлибә идек. Беренче көнне үк үзебезгә яңа дуслар таптык. Араларында Алмания, Албания, Сербия, Грузия, Алжир, Әфганстан, Казакъстаннан килгәннәре дә бар. Бер-беребез белән, әлбәттә, төрек телендә аралаштык.

Көн саен сәгать 9дан 13кә кадәр төрек телен өйрәндек. Дәресләр бик кызыклы итеп оештырылды: төрек җырларын да җырладык, биюләрен дә өйрәндек, милли костюмнарын да киеп карадык. Мөгаллимнәребез дә бик ачык күңелле һәм мөлаем булды.

Программада укудан тыш күңел ачу чаралары да каралган. Каппадокия тауларын, оча торган баллоннарны, VI гасырдан калган архитектура ядкәре – 80 метр җир астында сакланган Деринкуйю шәһәрен дә күрергә өлгердек. Шулай ук атта йөрдек, квадроциклларда җилдердек, көймәдә йөздек. Әлбәттә инде, төрекләрнең зәркән салонында да булдык. Бирегә, кая барсак та, безне шатланып каршы алдылар, хәтта кибетләрдә чәй белән дә сыйладылар.

Төркиянең җанга сихәт бирә торган һавасы, күңелле кичәләре һәм, әлбәттә, туган телебезгә кардәш булган төрек теле безне рухи яктан сихерләде, күңел түрендә якты, матур хатирәләр калдырды.

Үзебезнең тәэсирләребезне башкалар белән уртаклашу өчен, кайткач, без КФУда беренче курс студентлары белән очрашу уздырдык. Очрашуда Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәнияте бүлеге мөдире Ә.Ш.Юсупова, татар әдәбияты кафедрасы профессоры, филология фәннәре докторы Х.Й.Миңнегулов, Юныс Әмрә институтының Казандагы үзәге директоры Ихсан бәй Демирбаш һәм үзәкнең координаторы Эльмира ханым Хәбибуллина, төрек теле укытучыбыз Р.Р. Хөснетдинов та булды. Соңыннан безне Төркия Республикасының Казандагы Генераль консулы **Турхан Дилмач** кунакка чакырды, төрек илендә алган белемнәребез, тәэсирләребез турында сорашты. Очрашуга институтыбыз директоры, филология фәннәре докторы, профессор Радиф Рифкать улы Җамалетдинов та килде.

Иң мөһиме, без төрек телен өйрәндек, үзебезгә яңа һәм мәңгелек дуслар таптык. Төрле илләрдән булсак та, аралашып торабыз, очрашырга да сүз куештык!

Белми калма!

Казан (Идел буе) федераль университетының беренчел профсоюз оешмасы Россия Федерациясенең белем һәм фән өлкәсе хезмәткәрләре профсоюзының бер бүлекчәсе һәм Татар республикакүләм профсоюз оешмасының бер тармагы булып тора.

# Ярдәм кирәк булса...

Айгөл АБДРАХМАНОВА

Профсоюз оешмасының төп максаты – барлык студентларның иҗтимагый-икътисади, гражданлык хокукларын яклау һәм саклау.

КФУның беренчел профсоюз оешмасы уку йортына кендез йөреп, түләүсез бүлектә укучы студентларга матди ярдәм күрсәтә. Матди ярдәм алу өчен, гариза тутырып, тиешле документларны профсоюз оешмасына китерергә кирәк. Моннан тыш, профсоюз оешмасы электрон ячык, ягъни транспорт картасына киткән акчаларның билгеле бер күләмен кире кайтару мөмкинлеген дә бирә. Социаль яклауга мохтаж булган студентларны профсоюз оешмасы социаль туклану талоннары белән тәэмин итә.

Матди яки социаль ярдәм буенча барлык гаризалар да КФУның «УНИКС» бинасында, 108нче бүлмәдә кабул ителә.

Моннан тыш, КФУның беренчел профсоюз оешмасы студентларны кичәләр белән аралашу сәләтен, лидерлык сыйфатларын үстерергә, белемнәрен арттырырга һәм үз хокукларын якларга өйрәтә.

2015-2016 нчы уку елында КФУ профсоюз оешмасы кадрлар потенциалын үстерүгә юнәлтелгән «Золотой актив», профбюро житәкчеләренең белемнәрен арттыру белән шөгыльләнә торган «Студенческий адвокат», «Молодые лидеры Федерального» активистлар мәктәбе, «Электронный профгруппорг» проектларын һәм һәр студентның йөрәген ешрак тибәргә мәҗбүр итә торган «Студент года» бәйгеләрен уздырачак.

• Туган тел сагында

# Мин ни өчен татар журналистикасына укырга кердем?

Әлеге сорауга Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институтының татар журналистикасы кафедрасының беренче курс студентлары җавап бирде.

## Милләтемнең киләчәген күзаллыйм

**Лилия Туктарова**



Беренче язмаларымны, шигырьләремне туган телемдә иҗат итә башладым. Бу сәләтемне күреп, «Ялкын» журналының баш мөхәррире Йолдыз Миңнуллина миңа берәр фильмга карата фикер язып чыгарга тәкъдим итте. Шулай итеп минем беренче язмам татар телендә дөнья күрде.

Кечкенәдән үк татарча газета-журналлар укып, ТНВ каналында «Халкым минем», «Татарлар» тапшыруларын карап үстем, шуңа күрәдер мин үз алдыма татар халкына хезмәт итүчеләрнең берсе булырга тиешмен дигән максат куйдым. Киләчәктә үземне татар журналисты итеп күрәм.

Татар халкының тарихын өйрәнү журналистның иң беренче адымнары булырга тиеш. Гимназиямдә татар дөньясын ныклап өйрәнә башлагач, миңа укытучым гимназиябез тарихын татар телендә язып карарга кушты. Нәтиҗәдә, мине гимназия журналисты итеп күрә башладылар. Гореф-гадәтләрне саклау, халкыбызның тормышында катнашу журналистның төп миссиясе булырга тиеш. Гимназиянең активисты буларак, укытучылар миңа, команда туплап, «Мин татарча сөйләшәм» кысаларында үткәрелә торган «Татар дозор» уенында катнашып карарга кушты. Команда туплап, катнашырга булдым. Татар телендә иркен сөйләшү, җаваплылык, житезлек нәкъ менә безнең командага хас иде. Шулай итеп, 2015 нче елның «Татар дозор» уенының җиңүчеләре без булдык.

Татар яшьләре дөньясында кайнау миңа бик ошап китте. Соңрак мин Бөтендөнья татар яшьләре форумы уздыра торган «Печән базары» фестиваленә волонтер буларак бардым. «Печән базары» Казан татарлары өчен мәдәни һәм иҗтимагый үзәк булып торды. Ул сату-алу урыны гына түгел, ә Казан татарлары очрашып, күрешеп, бер-берсенең хәлен белеп тору урыны да булды. Үземне киләчәктә татар милләтенең тарихын өйрәнүче, бай киләчәген төзүче, милләтемне алга чыгаручы татар журналистларының берсе буларак күзаллыйм.

## Үзеңнән башларга кирәк

**Гөлгенә Гыймадова**



Кайвакыт күңелдә ниндидер бер фикер туа да, сине борчуга сала. Ул хәтта төн йокыларын качырырга мөмкин. Аны халыкка җиткерәсе килә, аңа колак салуларын телисең. Моның өчен дөрес дәлилләр табарга, ышандыра белергә кирәк. Журналистика нәкъ менә ышандыру көченә ия булган кешеләр өчен дип уйлыйм.

Кешене журналист булырга өйрәтеп булмый дип тә әйтәләр. Чөнки ул яшәү рәвеше, күңел халәте. Мине исә бу һөнәрнең тормышны яңа төсләр белән бизәве кызыктыра. Төрле кичәләр, очрашулар, әңгәмәләр, тормышның кайнап торуы – моннан да күңеллерәк нәрсә бар соң?! Журналист яңалыкны алдан белә, аңа бәя бирә.

Чын журналист булыр өчен, тормыш багажының саллы булуы бик мөһим. Бу уңайдан, яраткан журналистым Кит Уотерхаусның тормыш юлын үрнәк итәсем килә. Бөекбританиядә туган малай уналты яшендә мәктәптә укуын ташлый. Тормыш төбеннән күтәрелер өчен,ә аңа шактый тырышырга туры килгән. Нәтиҗәдә, ул кино, пьеса, мюзикл, телевизион сериалга нигез булган «Билли-алдакчы» дигән китап язган. Атаклы колумнист журналистиканы – әдәбият, әдәбиятны журналистика белән бәйләгән. Публицистик язмаларда исә туган телгә кагылган проблемаларны күтәргән. Милли журналистиканың төп проблемаларыннан берсе – туган тел мәсьәләсе. Барыбызга да туган телнең әһәмияте кимүе мәгълүм. Гаиләдә ана телен рус теле алыштыра. Балалар бакчасы, мәктәпләрдә дә туган телгә игътибар кими бара. Бу исә милли матбугат, радио-телевидениенең юкка чыгуына китерергә мөмкин. Менә шуңа мин милли журналистиканы сайладым, чөнки үзгәрүне үзеңнән башларга кирәк.

## Журналистлык минем канымда

**Илсинә Тимерова**



Журналистика белән мин күптәннән таныш. Әтием дә, әнием дә журналистлар. Һөнәр белән танышуым, әлбәттә, шигырьләр язудан башланды. Аннан хикәяләр... Һәм газеталарга яза башладым. Гел язасы, иҗат итәсе килде. Синең язмаңны укыйлар, мактыйлар.

Ә инде ни өчен нәкъ менә татар журналистикасын сайладың дип сорасалар, җавабым бик гади: мин татар баласы. Туганнан бирле татар мохитендә, татар телендә аралашып үскәнмен. Үземнең Татарстанда яшәвемә бик горурланамын! Карагыз, нинди үзгәрешләр кичерде безнең Казан, нинди генә зур масштаблы вакыйгалар үткәрелми монда. Шуңа да, бер дә оялмыйча, рәхәтләнеп татар телендә сөйләшәмен, җырлыймын да, биимен дә. Татар китапларын укыйм, татарча шигырьләр язам. Ягъни татар телен белсәм дә, телемне тагы да баетырга тырышам.

Тик шуңа карамастан, татар теле хәзерге яшьләр арасында бик популяр түгел. Татар кешесенең, телен сындырасындыра кыланып, рус телендә аралашканын күргәч, аптырап каласың. Үз телеңнән оялу үз милләтеңнән баш тарту белән бер бит инде ул! Менә шундый хәлләрне булдырмас өчен, татар милләтенең яшәешенә әзрәк булса да үз өлешемне кертәсем килә. Татар телен Татарстанда гына түгел, ә башка илләрдә дә танытырга кирәк! Бу минем зур хыялым. Чөнки элек-электән үк татар халкы иң бай милләт булып саналган. Танылган шагыйрьләребез Габдулла Тукай, Абдулла Алиш, Һади Такташларның әсәрләрен дә күп җирләрдә беләләр, укыйлар! Тик менә, кызганычка каршы, хәзерге вакытта татар теле әкренләп юкка чыга бара. Шулай булгач, әгәр дә без – яшьләр – моны вакытында аңлап алмасак, ахыргы чиктә инде бик соң булырга мөмкин. Шуның өчен мин нәкъ менә татар журналистикасын сайладым. Һәр кеше дә танылган шәхес булмаса да, үзенең милләтенә файда китерергә тиеш. Шул очракта гына аны саклап калып һәм алга таба үстереп булачак.

# Затлы укучыга – затлы газета

**Регина ШИҺАБЕТДИНОВА,**
Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты

КФУның татар журналистикасы кафедрасында күренекле шәхесләр белән очрашулар шактый еш үткәрелә. 1 октябрь көнне, мәсәлән, Милли китапханәдә «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире һәм журналистлары белән күрешү булды.

Газетаның башында торучы Вахит Имамов, бераз вакыт газета төзелеше белән таныштыргач, көн кадагында булган мәсьәләләргә күчте. Язучы һәм журналист буларак, билгеле, аны үзенең төп эш коралы – телнең халәте, аның югала баруы борчый. Милләтне телсез калудан коткару өчен, уку йортларында үзгәрешләр кертә башларга кирәк, дигән фикердә ул. Чыгышында Вахит абый мәктәпләрнең тәмам руслашып бетүен, ә авыл җирендә бөтенләй ябылуын да искә алды. Хәер, уку йорты татар балаларына саф татарча белем бирә алмаса, аның эшләвеннән файда күп булырмы? «Мәктәп милләткә файда китермәсә, аның кирәге юк», – дип белдерде ул. Чыннан да, мәдәният белеменә сусаган җәмгыятькә татар милли мәктәпләренең нәкъ менә мәгърифәт белән





үрелеп килгән әхлакый вәгазе кирәк.

Татар журналистикасына килгәндә, Вахит Имамов журналистларның заман шәхесенә әйләнә белү сәләтенә басым ясады. Замана белән бергә атлар өчен, икътисад, сәнгать, архитектура кебек өлкәләрнең нигезләре белән таныш булырга кирәк, ди Вахит абый. Ә менә XXI гасырның төп билгесенә әйләнгән интернетка исе китми аның: «Анда бердәнбер нәрсә күңелне җылыта: безнең газетаны ала алмаган чит илдәге татарлар, бер кыенлыксыз рәсми сайтка кереп, безнең материалларны укый ала. Ә күләмле язмаларны берсе дә челтәрдән укып утырмаячак, мин моңа ышанмыйм. Димәк, басма версия дә, Интернет-версия дә булырга тиеш», – диде.

Милләт һәм телне саклауны пропагандалаучы, саф татар мәдәни ядкәрләренең кадерен белергә, үз фикереңне кыю әйтергә өндәүче Вахит Имамовның сүзен аның каләмдәшләре – «Мәдәни җомга»ның журналистлары Сөембикә Кашапова, Хәмзә Бәдретдинов һәм Илгизәр Зәкиев дәвам итте. Һәрберсе булачак журналистларга саллы киңәшләрен җиткерде. Хәмзә абый бүгенге көндә һәр язмада татар рухы булырга тиешлеген ассызыклады, авыллар тарихы, «онытылган яңа исемнәр», республикабыздан читтә яшәгән татар галимнәре, күренекле шәхесләре турында мәгълүматлар аеруча кызыклы, дип белдерде ул. Сөембикә апа: «Су коюдан» читтә булыгыз. Һәр язылган сүз әйтергә теләгән фикерне чагылдырырга тиеш», – диде. Тел мәсьәләсен дәвам итеп, Илгизәр Зәкиев русча фикерләүдән качарга өндәде.

• Сәяхәттән кайткач

Турист букчасы, биштәр таккан студентлар кичкә таба бер-бер артлы УНИКСка агыла башлады. Барысы – 41 кеше. Аларга мин дә килеп кушылдым. Әмма без турпоходка кырга да, елга ярына да чыгасы түгел, ә шушы кешеләр белән герой-шәһәр Волградка барасы. Бу – КФУның активист-студентларга Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган «Җиңү уты – буыннар хәтерендә» бәйгесе җиңүчеләре өчен бүләге.

# Волградта 2 көн

**Раил САДРЕТДИНОВ,** Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты



## Юл кешесенең юлда булуы хәерле...

Автобусыбыз салмак кына кузгалып китте. Барасы юлыбыз озын – тукталышлар белән 17 сәгать! Юлда күп йөрергә туры килсә дә, мондый озын сәфәргә чыкканым юк иде әле. Әмма үз уйларыма чумып, автобус тәрәзәсенә текәлеп барырга туры килмәде. Чөнки юлдашым Айзирәк Садыков – биология һәм химия укытучысы булырга әзерләнүче егет – үземнән дә шәбрәк булып чыкты. Җәйге практикасын ак диңгездә уздырган кеше буларак, аңа юл озын тоелмады. Сүз иярә сүз чыгып, әңгәмәдәшемнең энтомология (бөҗәкләр турындагы фән) белән кызыксынуы, үз коллекциясен җыюы, төркемнәрендә староста, кыскасы, уку алдынгысы икәнлеге дә ачыкланды.

## Тор, шәкерт, җиттек Волградка...

Әлбәттә, автобус «кучеры» безгә алай дип эндәшмәде. Әмма Волградка килеп җитүебезне сизмичә дә калганбыз. Ерактан – Мамай курганы биеклегеннән күренеп торган Ватан-Ана һәйкәле безнең нәкъ менә герой-шәһәр Волградта икәнлегебезне тиз төшендерде.

Волград – сәнәгать шәһәре. Шуңа да безне матур-матур биек йортлар, чиста урамнар, чәчәк клумбалары каршыламады. Болар урынына шәһәр өстен пәрәвез ятьмәсе кебек чорнап алган трамвай, троллейбус, электр чыбыклары, һәр бинаны, һәр йортны, кибет-сәүдә үзәкләренең һәр квадрат метрын чуарлап торган реклама сәлам бирде. Шәһәрдән алган беренче тәэсирләр шулардан гыйбарәт иде. Шәһәр үзе озын һәм тар. Буйга йөреп чыгу өчен 3,5 сәгать кирәк булса, аркылыга нибары 1,5 сәгатьтә дә үтеп була.

Биредә төп рольне тимер юл уйный, электричка да гади шәһәр җәмәгать транспорты булып санала. Ул Идел буйлап сузылган.



Шәһәр эчендә берничә поезд күпере бар. Шуларның берсе астыннан чыкканда, зур автобусыбыз «кысылып» кала язды. Шәһәр үзе 2018 елда узачак футбол чемпионатын кабул итәргә әзерләнә. Ул спортчыларны, кунакларны ничек йөртерләр?!

## «Отстроим тебя, родной Сталинград!»

Дәһшәтле сугыш көннәренең берсендә йорт диварына язылган: «Отстоим тебя, родной Сталинград!» сүзләренә сугыш афәтеннән соң кайсыдыр әллә шаяртып, әллә патриотизмга бирелеп, «Р» хәрефен өстәп куя.

Хәзерге шәһәр исеме Волградка 1961 елда, Сталинның шәхес культы фаш ителгәннән соң бирелә. Аңа кадәр Сталинград (1925 елдан 1961 елга кадәр), ә аннан да алдарак Царицын исемен йөртә. Волград – тарихи шәһәр. Илебезнең, халкыбызның язмышы хәл ителгән урын. Монда һәр нәрсә, һәр почмак, һәр адым җир Бөек Ватан сугышы белән бәйле. Аның урамнары буйлап йөргәндә, эчке горурлык та, шәһит булып киткәннәр алдында җаваплылык та тоясың. Юкса, мин атлап

*Ватан-Ана һәйкәленең гомуми биеклеге – 85 м, скульптура үзе – 52, кылыч – 33, кул – 20. Скульптураның авырлыгы – 8 мең тонна, үзе тимер-бетоннан корылган. Төзелү вакыты – 1959-1967 еллар, хезмәт итү вакыты – 100 ел*

йөргән урамда гына да күпме кешенең каны коелган, шушы җирдә күпме кеше үз илен сакларга ант эчкән... Әйтерсең, шушы кешеләр әле бүген дә шул йорт почмакларыннан карап тора.

Без хәрабәләрдән соң иң беренче торгызылган үзәк урамнарның берсе – Тынычлык урамыннан барабыз. Биредә урнашкан йортларның барысы да 1944-1949 елгылар. Алар зур һәм тупас 5 катлы сталинкалар. Үзләре, җитмәсә, соры төскә буялган, кайберләренең инде акшары да купкан. Казан үзәгендәге уйлап эшләнгән, нәфис йортлардан соң боларга бертөрле затлылык, зәвык җитми кебек тоелды. Әйтерсең, алардан күпме тырышып та җиткерә алмаган коммунизм, социализм өрәге чыгып тора... Урам исемнәре дә шуны ук хәтерләтә: Советская, Рабоче-Крестьянская, 50 лет Октября, 13-й Гвардейской дивизии.

## 85 метрлы хатын-кыз скульптурасы

Сугыштан соң шәһәрдә төзелгән иң беренче һәйкәл НКВДның 10 нчы дивизия сугышчыларына куелган. Чөнки иң беренче булып һөҗүмне нәкъ менә алар кабул итә. Гомуми биеклеге – 22 метр, чекист үзе – 5, пьедестал – 17 метр. Төп мәгънәсе – кылыч белән килгән кылычтан китәр. Шуның янында гына этләргә куелган һәйкәл. Бу дүрт аяклы дусларыбыз, үз гомерләрен аямыйча, кеше әйткәнне үтәгән, кеше боерыгы белән үлемгә барган, йөзләгән немец танкларын теге дөньяга озаткан.

Автобус тәрәзәсеннән күзем җимерек бер бинага төште. Казанда да мондый биналарны күргәнгә, гадәти күренеш булып тоелды ул миңа. (Һәркем чит җирдә дә үзенекен эзли бит). Әмма әлеге бина сугыштан соң тергезелмәгән биналарның берсе икән. Элек ул тегермән ролен үтәгән, бүген – Сталинград сугышы музей-панорамасы комплексы музее. Кызыл кирпечтән салынган ишек-тәрәзәсез, түбәсез бу коточкыч каркас безне шул еллар михнәтен, шул еллар дәһшәтен онытмаска өнди сыман.

Сталинград сугышы көннәре исәбенә туры китереп эшләнгән 200 баскыч (аларның һәрберсе 15 см биеклектә, 35 см киңлектә) үтәсе бар. Без Россиянең 7 нче хәзинәсе саналган, дөньяда биеклеге буенча Гиннесслар китабына кертелгән «Ватан-Ана» монументы астында басып торабыз. Экскурсоводыбыз китергән саннар шаккатыргыч: гомуми биеклеге – 85 м, скульптура үзе – 52, кылыч – 33, кул – 20. Скульптураның авырлыгы – 8 мең тонна, үзе тимер-бетоннан корылган. Төзелү вакыты – 1959-1967 еллар. Монументның хезмәт итү вакыты – 100 ел. Бүген ул биеклеге буенча дөньяда 11 нче урында. Чагыштыру өчен: Нью-Йорктагы Азатлык статуясы – 46 метр, Рио-де-Жанейродагы Христос-коткаручыныкы – 38.

Аның янында, Волградның кайнар сугышлар барган иң биек ноктасында басып торганда, курку да, горурлык та биләп алды үземне...

## 50 меңнән артык немец солдаты күмелгән зират

Әлеге объект сугыш аркасында юк ителгән Олы һәм Кече Россошки авыллары территориясендә урнашкан. Монда сугыш вакытында ук немец гаскәрләренең зираты була. 1993 елда барлык якынтирә өлкәләрдән һәм Сталинградның үзендә табылган немец җәсәдләрен бирегә җирләргә рөхсәт ителә. Бүген зиратны немецлар үзләре карап тора. Дивар итеп әйләндереп алынган түгәрәктә 40 меңнән артык немец солдаты ята. Диварда һәрберсенең исеме, туган һәм вафат булган көне, туу урыны күрсәтелгән. Немец солдатын идентификацияләү камил булган – алар тимер жетон асып йөргән, ә совет солдатының бар мәгълүматы үзе белән йөргән шешәдәге кәгазьдә сакланган. Шуңа да билгесез каберләр бүген дә әле ил буенча сибелгән. Зират янында гына күп итеп кублар урнаштырылган. Боларында шундый ук мәгълүмат белән хәбәрсез югалганнар урын алган.

Юлның сул ягында совет солдатларының каберлекләре. Элек бу зират булмаган. Бүген дә табылып торган совет сугышчыларының җәсәдләрен монда җирли башлаганнар. 18 меңнән артык үз илен саклаган кеше җирләнгән биредә. Күбесе – туганлык каберлекләрендә. Кайберсе – аерым каберлектә, ә кайберсенең исеме дә ачыкланмыйча калган. Зират эчендә Сталинградны яклап сугышкан Татарстан солдатлары өчен кабер ташы да куелган. Исемле ташлар арасында татар исем-фамилияле кешеләр дә бар.

Күп тәэсирләр, онытылмаслык хатирәләр бүләк итте миңа сентябрь көннәренең берсендә Волград. Кызыклы, мәгълүматка бай экскурсия бик тә файдалы булды.

Волград белән без кичке утлар кабынгач саубуллаштык. Әмма хушлашмадык. Шул ук юлны кабат үтәсе булса да, тизрәк кайтып җиттек шикелле. Кайтып җитүебез булды, көчле бер агымга килеп кушылдык. Миллионлы шәһәр булса да, Волградта тормыш алай ук тиз бармый кебек иде. Дала иркенлегенә ияләшкән күңел Казанның тар урамнарына сыймый иде инде – «бөке»гә эләктек, ә бит Волградта аның ни икәнен дә белмиләр...

Казан (Идел буе) федераль университеты коллективы, Социаль-фәлсәфи фәннәр һәм гаммәви коммуникация институты доценты **Фәрит Мәсгут улы Гыйниятовның** фаҗигале төстә вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең туганнарының һәм якыннарының тирән кайгысын уртаклаша.

Казан (Идел буе) федераль университеты коллективы, әнисе вафат булу сәбәпле, КФУның документлар әйләнеше һәм контрольлек идарәсе җитәкчесе **И.Р.Лукашинаның** тирән кайгысын уртаклаша.

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир в.б. - Л.Р.Сабирова
Иҗат коллективы: Р.Габдрахманова, А.Абдрахманова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.